**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Бәркәтә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге составына керүче Бәркәтә торак пунктында

**12 ноябрь 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең Бәркәтә торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан тыш.
2. Алынган акчаларны җибәрергә:

- **Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау** («Шушма» елгасы аша җәяүлеләр кичүен төзү, култыксаларны ремонтлау, такталар урнаштыру);
- **Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр челтәрләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Бәркәтә торак пунктында урамнарны яктыртуны монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланыла торган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- **Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәйге һәм кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, триммерлар сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы Р.М.Сибгатуллин